РАСЛЫЙМ
Г.Тукай исемендәге
Әтнә татар
дәүләт драма
театры директоры
____________
Зәйнуллин Л.И.
_____________2021г.

КИЛЕШЕНГӘН
Әтнә муниципаль
районы мәгариф
бүлеге җитәкчесе
____________
Мөхәммәтгалиева А.Ф.
_____________2021г.

КИЛЕШЕНГӘН
Әтнә муниципаль
районы мәдәният
бүлеге җитәкчесе
____________
Хәнәфиева А.Р.
_____________2021г.

**Гомәр Мәрдәнов исемендәге театр фестивале үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр.

1. Әлеге нигезләмә Гомәр Мәрдәнов исемендәге театраль фестивальне оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели (алга таба – Фестиваль).

## II. Фестивальнең максатлары һәм бурычлары.

2.1. Фестиваль танылган театр әһеле, легендар режиссер Гомәр Мәрдәновның исемен мәңгеләштерү, балаларда рухи мәдәниятне, татар халкының милли мирасына сак караш формалаштыру, туган телне саклау һәм үстерүгә теләктәшлек максатыннан үткәрелә.

2.2. Фестивальнең бурычлары:

– үсеп килүче буында татар язучылары һәм драматургларының иҗатын өйрәнүгә теләкне үстерү;
– укучы балаларның игътибарын театр сәнгатенә юнәлтү;
– балалар һәм яшүсмерләргә сәнгати-эстетик, әхлакый тәрбия бирү;
– иҗади сәләтле укучыларны эзләп табу, аларга ярдәм итү.

## III. Фестивальне оештыручылар.

3.1. Фестивальне оештыручылар:

– Габдулла Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театры;
– Әтнә муниципаль районының мәгариф бүлеге;
– Әтнә муниципаль районының мәдәният бүлеге.

## IV. Оештыру комитеты һәм жюри.

4.1. Фестивальнең оештыру комитеты:
–Фестивальнең нигезләмәсен эшли;
–Фестивальнең жюри составын формалаштыра;
– Фестивальнең бәяләү критерийларын билгели;
– Фестивальнең кайда һәм нинди вакыт аралыгында үткәрелүен билгели;
– Фестиваль җиңүчеләрен бүләкләүне оештыра.
4.2. Фестиваль жюрие:
– театр коллективларының постановкаларын бәяли һәм җиңүчене билгели.

## V. Фестивальдә катнашу өчен таләпләр.

5.1. Фестивальдә Әтнә муниципаль районы мәктәпләренең театраль коллективлары катнаша.

5.2. Спектакль татар телендә куелган булырга тиеш.

5.3. Постановкалар эчтәлекле булырга, әхлакый-эстетик принципларга нигезләнгән булырга тиеш.

## VI. Фестивальне үткәрү шартлары һәм тәртибе.

6.1 Фестивальне үткәрү өчен оештыру комитеты һәм жюри булдырыла. Оештыру комитеты Фестивальне үткәрү белән бәйле оештыру мәсьәләләрен хәл итә. Жюри Фестивальдә катнашучыларның постановкаларын карый, бәяли, җиңүчене ачыклый.

6.2. **1 этап** – мәктәп коллективы тарафыннан пьеса сайлау.

**2 этап** – заявка бирү.

**3 этап** – спектакльне сәхнәгә кую.

**4 этап** –спектакльне күрсәтү. Жюри, район мәгариф бүлеге һәм мәдәният бүлеге тарафыннан төзелгән график буенча, коллективларның чыгышын мәктәпләргә яки районның авыл клубларына барып бәяли.

**5 этап** – Габдулла Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театры сәхнәсендә Фестивальдә җиңгән спектакльне күрсәтү. Үткәрү вакыты – 2022 елның 19 марты.

## VII. Фестивальне финанслау.

7. Фестивальне финанслау спонсорлар ярдәме һәм театрның бюджет средстволары ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## VIII. Фестивальгә нәтиҗә ясау.

8.1. Фестивальдә катнашучыларның спектакльләре аерым критерийлар буенча бәяләнәчәк (актерлык осталыгы, сценография, пьесаның актуальлеге һәм эчтәлеге,

музыкаль бизәлеш, костюмнар, спектакльнең пластик чишелеше, тамашачыга тәэсире); нәтиҗәләр протоколларда гомумиләштереләчәк.

8.2. Иң югары балл җыйган театраль коллектив абсолют җиңүче дип танылa. Фестиваль нәтиҗәләре буенча Фестиваль катнашучылары Катнашучы Дипломнары һәм кызыксындыру бүләкләре белән бүләкләнә. Җиңүчегә кыйммәтле бүләк тапшырыла.

**Оештыру комитеты**

Зәйнуллин Ленур Ильфир улы – театр директоры
Садуллаева Райлә Равил кызы – директор урынбасары
Фазлыев Рамил Радик улы – театрның баш режиссеры
Галиев Рәмис Рәшит улы – диретор урынбасары, постановка бүлеге мөдире
Батталова Гөлүсә Рәшит кызы – директор урынбасары
Салихов Данил Хәбибрахман улы – театрның әдәби бүлек мөдире
Сәләхиев Раил Рәшит улы – драма артисты
Хөсәенов Фаяз Тәлгать улы – драма артисты
Хөсәенова Зөһрә Таһир кызы – труппа мөдире

**Жюри**

Фазлыев Рамил Радик улы – театрның баш режиссеры, ТР Атказанган сәнгать эшлеклесе
Галиев Рәмис Рәшит улы – диретор урынбасары, постановка бүлеге мөдире
Салихов Данил Хәбибрахман улы – театрның әдәби бүлек мөдире, драматург
Хәбибуллин Марат Мәхмүт улы – драма артисты, ТР Атказанган артисты
Мөхәммәтҗанова Гөлнар Равил кызы – "Әтнә таңы" газетасы баш мөхәррире, Әтнә халык театры артисты
Закирова Гөлшат Марс кызы – педагог, театрал
Хәнәфиева Алия Ринат кызы – мәдәният бүлеге җитәкчесе, хореограф.

**Гомәр Мәрдәнов исемендәге театр фестивалендә катнашу өчен**
**ЗАЯВКА**

| | |
|---|---|
| Мәктәп | |
| Коллектив исеме | |
| Коллективның җитәкчесе, контактлар | |
| Спектакльнең исеме | |
| Автор | |
| Жанр | |
| Катнашучылар саны | |
| Катнашучылар исемлеге | |

Заявкалар atnya-teatr@mail.ru электрон адресына, “Фестиваль Заявка” дигән тамга салынып җибәрелергә тиеш.

Сораулар булганда,

Хөсәенова Зөһрә Таһир кызына (театрда труппа мөдире)
Тел. 89178620567

Батталова Гөлүсә Рәшит кызына (директор урынбасары)
Тел. 89274033969

мөрәҗәгать итәргә мөмкин.